**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

«17» январь 2022 ел Мәләкәс авылы № 1

Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегенең концессион килешү төзү планлаштырылган муниципаль милеге исемлеген раслау турында

«Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон, Монополиягә каршы хезмәтнең 2010 елның 10 февралендәге «Аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, милек белән ышанычлы идарә шартнамәләрен, дәүләт яки муниципаль милеккә карата хокукларны күчүне күздә тоткан башка шартнамәләрне төзү хокукына конкурслар яки аукционнар үткәрү тәртибе һәм күрсәтелгән шартнамәләрне төзү конкурс формасында сатулар үткәрү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин милек төрләре исемлеге турында» 67 номерлы боерыгы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегенең концессион килешү төзү планлаштырылган муниципаль милеге исемлеген кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар Интернет челтәрендә www.torgi.gov.ru рәсми сайтында һәм Тукай муниципаль районы сайтында урнаштырылырга тиеш.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мәләкәс авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе Ю.П. Васильев